КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 1 февраль г.Казань № 81

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Конституция судын бетерү, Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчен югалтуын тану турында» 2022 елның 21 октябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру буенча чаралар хакында)» 2022 ел, 10 ноябрь, 1190 нчы карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Конституция судын бетерү, Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчен югалтуын тану турында» 2022 елның 21 октябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру буенча чаралар хакында)» 2022 ел, 10 ноябрь, 1190 нчы карарына, түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«3. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

ликвидация комиссиясе рәисенең һәм рәис урынбасарының хезмәте өчен түләү ликвидация комиссиясе әгъзаларының хезмәтенә түләү өлешендә ликвидация чараларын үткәрүгә чыгымнарның сметасында каралган чаралар чикләрендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вакытлы хезмәт шартнамәләре белән билгеләнгән шартларда гамәлгә ашырыла;

ликвидация комиссиясе рәисе ликвидация комиссиясенә йөкләнгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру максатында Россия Федерациясе гражданнары белән

ликвидация чараларын үткәрүгә чыгымнарның сметасында каралган чаралар чикләрендә эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) гражданлык-хокукый характердагы килешүләр төзергә хокуклы.».

2. Бу карарның гамәле 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин